Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Бортас авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

«13» апрель 2019 ел №108

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Бортас авыл
җирлеге Советының 2016 елның
21 апрелендәге «Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Бортас авыл җирлеге муниципаль
берәмлегендә муниципаль хезмәт турында»
гы 18 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 15 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 20 декабрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге Советының 2016 елның 21 апрелендәге 18 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә” гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяны 3 нче пункт белән тулыландырырга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җитәкче булган муниципаль хезмәткәр җирле үзидарә органында, җирлек сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайлау профсоюз органында, җирлек сайлау комиссиясе аппаратында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмый.».

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Бортас авылы, Пионер ур., 1;
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Чаллы авылы, Ленин ур., 43,
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Бортас авылы, Ленинградская ур 27, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Бортас авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Бортас авыл җирлеге Советы Рәисе Р.С.Сагдиев